ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Экология» илкүләм проекты составына керүче «Иделне чистарту» федераль проектын Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру турында мәгълүмат хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министры А.В. Шадриковның «Экология» илкүләм проекты составына керүче «Иделне чистарту» федераль проектын Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру турында мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. «Экология» илкүләм проекты составына керүче «Иделне чистарту» федераль проектын Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры А.В. Шадриковның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы белән берлектә «Экология» илкүләм проекты составына керүче «Иделне чистарту» федераль проекты күрсәткечләренең планлаштырылган саннарына ирешүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына су объектларының яр буе саклау полосалары чикләрендә җирләрне сөрү фактларын бетерүне, терлекчелек калдыкларын эшкәртүнең алдынгы технологияләрен гамәлгә кертүне һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре тарафыннан җитештерү һәм куллану калдыкларын, шул исәптән терлекчелек калдыкларын, су объектларының су саклау зоналары һәм яр буе саклау полосалары чикләрендә урнаштыру (туплау) фактларын булдырмауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Идел-Кама регионара идарәсенә, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына тиешле вәкаләтләр кысаларында прокуратура органнары белән берлектә законсыз булдырылган җир

кишәрлекләрен ачыклау эшен дәвам итүне һәм яр буе полосаларын төзелмәләрдән һәм корылмалардан бушату буенча дәгъвалар бирү эшен оештыруны тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

5.1. Федераль һәм региональ проектлар кысаларында төзелгән (реконструкцияләнгән) чистарту корылмаларын муниципаль берәмлек балансына алуны һәм аларны шул исәптән табигатьне саклау законнарын үтәү өчен җаваплы оешмага кыска срокларда файдалануга тапшыруны тәгәлләргә.

5.2. Чистартуны норматив күрсәткечләргә җиткереп, муниципаль берәмлекнең торак-коммуналь хуҗалыгының чистарту корылмалары эшен тикшереп торуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 15 апреле
№ 2426-VI ДС